Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы

**КАРАРЫ**

28 май, 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шихазда авылы, Сула ур., з/у 22 адресы буенча кадастр номеры 16:33:120301:783 булган җир кишәрлегендә мәчет төзү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының 2017 елның 18 августындагы 65 номерлы карары (2017 елның 15 декабрендәге 79 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 92 номерлы, 2019 елның 08 октябрендәге 137 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 60 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 69 номерлы үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә, кергән гариза нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шихазда авылы, Сула ур., з/у 22 адресы буенча кадастр номеры 16:33:120301:783 булган җир кишәрлегендә мәчет төзү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет);

2.2. Җәмәгать фикер алышуларын үткәрү датасы һәм вакыты - 09.06.2025 елның 9 июнендә 16.00 сәгатьтә;

2.3. үткәрү урыны - «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең 23 нче номерлы Шихазда авыл китапханәсе-филиалы. Адресы: ТР, Питрәч районы, Питрәч авыл җирлеге, Шихазда авылы, Центральная урамы, 51 йорт;

2.4. Авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү

урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала торган адрес: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Совет урамы, 18 йорт, e-mail: pes.pes@tatar.ru.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Шихазда авылы, Сула ур., з/у 22 адресы буенча кадастр номеры 16:33:120301:783 булган җир кишәрлегендә мәчет төзү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышуларны әзерләргә һәм үткәрергә;

3.2. Иҗтимагый фикер алышулар булуын Питрәч муниципаль районы Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Питрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга;

3.3. «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Сөләйманов